БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» 10 2021 г. № 336

«Кайтаваз» ТРК» муниципаль бюджет учреждениесенә субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пункты нигезендә, «Кайтаваз» ТРК» муниципаль бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Кайтаваз» ТРК» муниципаль бюджет учреждениесенә субсидия бирү тәртибен расларга

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Кайтаваз «ТРК» муниципаль бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пункты нигезендә эшләнде.

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетыннан (алга таба - бюджет) субсидияләр бирү процедурасын, шулай ук аларны бюджетка кире кайтару тәртибен билгели.

1.3. Субсидияләр бирү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Оештыручы) исеменнән Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасы тарафыннан тиешле финанс елында Оештыручыга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә җыелма бюджет язмасы нигезендә гамәлгә ашырыла

1.4. Субсидияләр бирү субсидияләр алучыларның муниципаль берәмлек бюджеты алдында акчалата йөкләмәләр буенча түләү вакыты узган (җайга салынмаган) бурычлары булмаган очракта гына бирелә.

1.5. Россия Федерациясе бюджет системасы алдында салым бурычлары булмаган очракта.

## 2. Субсидияләр бирү тәртибе

2.1. Финанс елы дәвамында бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр булу тора:

- муниципаль йөкләмәне Оштыручы тарафыннан расланган тиешле финанс елына яисә тиешле финанс елы һәм план чорына муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) (тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет расланган очракта);

- Оештыручы һәм бюджет учреждениесе арасында «Кайтаваз» ТРК» муниципаль бюджет учреждениесенә муниципаль хезмәт күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмәне финанс яктан тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында төзелгән килешү (алга таба - килешү).

2.2. Күрсәтелгән килешү субсидия бирү максатларын һәм шартларын, хокукларны, шул исәптән Оештыручының бюджет учреждениеләре тарафыннан килешү шартларын үтәүне тикшерүгә хокукын, якларның бурычларын, җаваплылыгын, субсидия күчерүнең күләмен һәм вакытларын, субсидия бирүне туктатып тору, күләмен үзгәртү һәм бюджетка кире кайтару нигезләрен, финанс елы дәвамында субсидия бирүнең периодик рәвештә кабатланып торуын, субсидияне бюджетка кире кайтару тәртибен һәм вакытын билгели.

2.3. Субсидияне күчерү Оештыручы тарафыннан бюджет учреждениесенә аның шәхси счетына гамәлгә ашырыла.

2.4. Субсидияләр Оештыручы тарафыннан, килешүнең аерылгысыз өлеше булган субсидияләрне күчерү графигы нигезендә, агымдагы чор чыгымнарын тәэмин итүче күләмдә айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә күчерелә.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмәне үтәү вакыты дәвамында субсидияләр күләмен үзгәртү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла: муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмәне тиешенчә үзгәрткәндә күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр (эшләр башкару) күләме (эчтәлеге) күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү;

Физик һәм (яисә) юридик затларга муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм (яисә) муниципаль мөлкәтне карап тотуга норматив чыгымнар күрсәткечләрен үзгәртү; муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс яктан тәэмин итү өчен чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре размерын үзгәртү.

### 3. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

3.1. Килешүдә билгеләнгән шартларны үтәмәгәндә һәм (яки) бозганда, Оештыручы карары буенча субсидияләрне күчерү хокук бозуларны бетергәнче туктатыла.

3.2. Субсидияне максатсыз файдалану, муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмәнең тулы яки өлешчә үтәлмәве (күрсәткечләргә киле җитмәве), килешүдә билгеләнгән аларны юк итү мөмкин булмаган башка шартларны бозу факты ачыкланган очракта, әлеге бозулар ачыклангannan соң өч эш көне эчендә Оештыручы тарафыннан ачыкланган бозулар турында акт (алга таба - акт) төзелә.

3.3. Акт төзелгәннән соң 10 эш көне эчендә Оештыручы тарафыннан бирелгән субсидияләрне бюджетка кире кайтару турында карар кабул ителә һәм бюджет учреждениесенә субсидияләрне кире кайтару турында хәбәрнамә (алга таба - хәбәрнамә) җибәрелә.

3.4. Оештыручы бюджет учреждениесенә хәбәрнамә җибәргән көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Балтач районы территориаль бүлегенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасына актның һәм хәбәрнамәнең күчермәләрен җибәрә.

3.5. Бюджет учреждениесе бирелгән субсидияләрне кире кайтару турында хәбәрнамәдә билгеләнгән вакытта максатсыз файдаланган күләмдә субсидияләрне кире кайтарырга тиеш. Субсидияләрне ирекле рәвештә

бюджетка кире кайтарудан баш тартканда, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

3.6. Бюджет учреждениеләре субсидияләрдән максатчан файдаланган өчен, шулай ук килешүдә каралган шартлар нигезендә субсидиядән файдалану турында Оештыручыга бирелгән белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы була һәм ай саен Оештыручыга субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшыра.

3.7. Субсидияләрдән максатчан файдалануны Оештыручы контрольдә тота.